СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2023 г. Заинск № 123

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә территорияне планлаштыру проекты, территорияне межалау (чикләү) проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе турында» 2022 елның 04 мартындагы 87 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясы 2 пункты икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә территорияне планлаштыру проекты, территорияне межалау (чикләү) проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе турында» 2022 елның 04 мартындагы 87 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй

муниципаль районының Зәй шәһәрендә территорияне планлаштыру проекты, территорияне межалау (чикләү) проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе турында нигезләмәнең 2.6 пунктында, "бер ай һәм өч айдан артык" сүзләрен "үндүрт көн һәм утыз көннән артык" сүзләре белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN. RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының җир мәсьәләләре, экология һәм ТКХ буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**